**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**23.12.2020** **№ 958**

**Биектау муниципаль районы халкына социаль (мунча) хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә алынган мунчаны карап тоту чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр алучылар исемлеген раслау турында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы бюджетыннан юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 елның 22 октябрендәге 2272 номерлы карары, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы бюджетыннан юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча комиссия составын раслау турында» 2018 елның 12 декабрендәге 2691 номерлы карары (26.11.2020 №904 карар редакциясендә), 2020 елның 23 декабрендәге 2/2020-СУ номерлы Биектау муниципаль районы бюджетыннан юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча комиссиясе утырышы беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы халкына социаль (мунча) хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә алынган мунчаны карап тоту чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр алучылар исемлеген расларга (1 нче кушымта);
2. Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына Биектау муниципаль районы халкына социаль (мунча) хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә алынган мунчаларны карап тоту чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) район бюджетының калган акчалары исәбеннән субсидияләрне бүлеп бирергә тәкъдим итәргә;
3. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталының Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе                                        Д.Ф. Шәйдуллин